КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 23 апрель г.Казань № 332

Акцияләрнең (өлешләрнең) 100 проценты Татарстан Республикасыныкы булган юридик затларга әлеге затлар милкендә булган капиталь төзелеш объектларына һәм (яки) алар тарафыннан күчемсез мөлкәт объектларын сатып алуга капитал салуларны гамәлгә ашыруга, алга таба мондый юридик затларның устав капиталларын Россия Федерациясе законнары нигезендә арттыру белән Татарстан Республикасы бюджетыннан бирү тәртибен раслау турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78 статьясындагы 8 пункты нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Карарга теркәлгән Акцияләрнең (өлешләрнең) 100 проценты Татарстан Республикасыныкы булган юридик затларга әлеге затлар милкендә булган капиталь төзелеш объектларына һәм (яки) алар тарафыннан күчемсез мөлкәт объектларын сатып алуга капитал салуларны гамәлгә ашыруга, алга таба мондый юридик затларның устав капиталларын Россия Федерациясе законнары нигезендә арттыру белән Татарстан Республикасы бюджетыннан бирү тәртибен расларга.

2. Бу карар белән расланган Тәртипнең 7 пунктындагы «е» пунктчасы нигезләмәләре сатып алулар өлкәсендә бердәм мәгълүмат системасында урнаштырылган сатып алуларны гамәлгә ашыруга бәйле мөнәсәбәтләргә яисә аларда катнашырга чакыру 2019 елның 1 июненә кадәр җибәрелсә, шулай ук 2019 елның 1 июненә кадәр төзелгән шартнамәләргә карата кулланылмый.

3. Бу карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Икътисад, финанслар һәм дәүләт мөлкәте белән эш итү идарәсенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин